РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с. Тюлячи КАРАР

«26» март 2025ел № 52

Мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр төрендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларны үтәү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 32.13 статьясы, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 июлендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 109.2 статьясы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр төрендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләренә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү мәсьәләләре буенча суд приставлары хезмәте белән үзара хезмәттәшлек өчен җаваплы затларны билгеләргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләренә Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексында, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законда каралган бурычлар йөкләнә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 03 2025 № 52
карарына кушымта

Мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр төрендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеге

| № т/б | Оешманың исеме | Объектлар һәм территорияләр урнашу исемлеге | ИНН | Башкарыла торган эшләр төре | Устав нигезендә оешманың эшчәнлеге юнәлеше |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты | Әбде авыл җирлеге (Әбде, Тактамыш, Ташлыяр т.п) | 1619004394 | 1. Урамнарны, паркларны, скверларны, ял зоналарын һәм ишегалды территорияләрен җыештыру. 2. Парклар, скверлар, ял зоналарын төзекләндерү, санитар чистарту һәм яшелләндерү. 3. Агачлар һәм бордюрлар буяу. 4. Юл капламын юл техникасы өчен мөмкин булмаган урыннарда пычрактан, чүп-чардан, кардан, | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 2. | Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты | Айдар авыл җирлеге (Айдар, Субаш, Борчаклы Яз т.п.) | 1619004436 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 3. | Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башкарма комитеты | Алан авыл җирлеге (Алан, Балыклы, Күкчә, Ключище т.п.) | 1619004387 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 4. | Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге башкарма комитеты | Баландыш авыл җирлеге (Баландыш, Урта Мишә т.п.) | 1619004362 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 5. | Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Нырсы авыл җирлеге (Олы Нырсы, Кече Нырсы, Кече Мирәтәк, Иске Карабаян, Карабаян, Тәмте т.п.) | 1619004450 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Мишә авыл җирлеге (Олы Мишә, Түбән Саурыш, Олы Саурыш, Җәнәй т.п.) | 1619004468 | бозлавыктан чистарту.<br>5. Йөк төяү-бушату эшләре.<br>6. Зиратлар территорияләрен җыештыру | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 7. | Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Мәтәскә авыл җирлеге (Олы Мәтәскә, Лесной, Югары Мәтәскә, Ямбулат, Тямти Метески) | 1619004411 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 8. | Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге (Югары Кибәхуҗа, Максабаш, Төрек-Тәмте т.п.) | 1619004443 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 9. | Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге (Кече Кибәхужа, Казаклар, Олы Кибәхуҗа т.п.) | 1619004429 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 10. | Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты | Иске Җөри авыл җирлеге (Иске Җөри, Олы Тиләҗе, Каращирмә, Орымширмә, Яңа Җөри, Алан Җөри т.п.) | 1619004404 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 11. | Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты | Теләче авыл җирлеге (Теләче, Комаровка, Ачы, Екатериновка т.п.) | 1619004203 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 12. | Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты | Үзәк авыл җирлеге (Үзәк, Шармаш, Сауш, Алга, Петровский, Пановая Гора т.п.) | 1619004370 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 13. | Теләче муниципаль районы Шәдке авыл җирлеге башкарма комитеты | Шәдке авыл җирлеге (Шәдке, Югары Мирәтәк, Олы Мирәтәк, Удельный Мирәтәк) | 1619004482 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |